Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

***А.М. Гайнетдинов***

# КАЗАННЫҢ БИШБАЛТА БИСТӘСЕ ЭПИГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Казан – 2018

УДК 930.27:94(470.41)
ББК 63.2(2Рос.Тат)+ 63.3(2Рос.Тат)
Г 14

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТОРАК ПУНКТЛАРЫНЫҢ ТАРИХЫ» сериясе

**Фәнни мөхәррир:**
тарих фәннәре докторы, ТР ФА академигы *Р.Р. Салихов*

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы, профессор *М.И. Әхмәтҗанов*
тарих фәннәре кандидаты *И.Җ. Фәйзрахманов*

***Гайнетдинов А.М.***
**Г 14 Казанның Бишбалта бистәсе эпиграфик истәлекләре.** – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2018. – 68 б.

ISBN 978-5-94981-279-2

Китапта Казан шәһәрендә урнашкан Бишбалта бистәсе зиратында хәзерге көнгә хәтле сакланып калган гарәп язулы татар эпиграфик истәлекләренең текстлары, аларның хәзерге телгә күчермәләре китерелде. XIX гасырдан алып 1933 елга хәтле куелган 25 кабер ташы исәпкә алынды.

Хезмәт татар төбәк тарихын, тарихи-мәдәни мирасыбызны өйрәнүче галимнәргә, мөгаллимнәргә, аспирантларга, гомумән, татар халкы тарихы белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

© Гайнетдинов А.М., 2018
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2018

# КЕРЕШ

Халкыбыздан безгә мирас буларак гаять күп сандагы тарихи-мәдәни истәлекләр сакланып калган, шул исәптән гарәп графикасында язылган борынгы кабер ташлары да бихисап күп. Алар халкыбыз тарихын, мәдәниятен, телен өйрәнүдә, һичшиксез, әһәмиятле роль уйный.

Каберләргә таш кую традициясе безгә борынгы төркиләрдән үк килә. 731, 734 елларда ук Күлтәгин, Билге каган кебек Төрки каганат җитәкчеләре истәлегенә рун хәрефләре белән язылган ташбилгеләр куелуы мәгълүм. Шулай ук төрки халыкларда каберләр өстенә балбаллар (кеше рәвешендә ясалган таш сын) кую гадәте таралган булган, алар да, үзенә күрә, кабер ташы функциясен үтәгән, җиңелгән дошманнарны рухсыз итү символы буларак кулланылган[1]. Төркиләр ислам динен кабул иткәннән соң, руник язулы ташлар һәм балбаллар гарәп телендәге дини гыйбарәләр, Коръән аятьләре, хәдисләр язылган ташбилгеләргә алыштырылган. Гарәп графикасындагы беренче ташъязма истәлекләр 1161–1162 елларда ук төрки кабиләләр төзегән Караханилар дәүләтендә куела башлаган[2].

Тарихтан билгеле булганча, Болгар шәһәре Алтын Урда тарафыннан яулап алынганчы, болгарларда, ягъни безнең җирлектә, бөтенләй каберләр өстенә язулы ташлар кую гадәте юк иде. Күренекле татар галимнәре М.И. Әхмәтҗанов, Р.Ф. Фәхретдинов исбатлап язганча, бу традиция

---

[1] Әхмәтҗанов М.И. Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 2011. – Б. 5.

[2] Джумагулов Ч. Эпиграфика Киргизии. Выпуск 3 / Ч. Джумагулов. – Фрунзе: Изд-во «Илим», 1987. – С. 60.

аларга Алтын Урда цивилизациясе аша кергән[3]. Шул чордан башлап безнең җирлектә кабер ташларына язулар төшерү гадәте киң таралып, бүгенге көнгә хәтле дәвам итә. Ортодоксаль ислам дине кабер өстенә нинди дә булса таш куюга, корылма коруга тискәре караса да[4], безнең халык VIII гасырдан ук килгән гореф-гадәтләрен югалтмаган, саклаган, буыннан-буынга тапшырып килгән.

Соңгы елларда тарихи-мәдәни истәлекләргә игътибар көчәеп китте һәм аларны өйрәнү дә бик актуаль юнәлешкә әверелде. Шуңа күрә татарлар яшәгән һәр төбәк җентекләп өйрәнелергә тиеш, әби-бабаларыбыздан сакланып калган бер генә эпиграфик ядкәрне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамый, аларның һәрберсен түкми-чәчми халыкка кайтаруда җиң сызганып эшләү таләп ителә.

Кызганыч ки, моңарчы әле Бишбалта зираты эпиграфик планда бөтенләй өйрәнелмәгәнгә, андагы хәзерге көннәргә кадәр юкка чыкмыйча сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен 2017 елның апрель аенда ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан фәнни экспедиция оештырылды. Анда без фәкыйрегез, Айдар Ногманов, Сайрус Хәмидуллин һәм Олег Владимиров (аларга күрсәткән ярдәмнәре өчен олы рәхмәтебезне белдерәбез) катнашты.

---

[3] Кара: Әхмәтҗанов М.И. XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 2011. – Б. 9; Фахрутдинов Р. Золотоордынский Булгар / Р. Фахрутдинов // Татарская археология. – 2006. – № 1–2. – С. 71.

[4] Поляков С.П., Черемных А.И. Погребальные сооружения населения долины Заревшана / С.П. Поляков, А.И. Черемных // Домусульманские верования и обряды Средней Азии. – М.: Наука, 1977. – С. 277; Мухаметшин Д.Г. Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Серия «Археология евразийских степей» / Д.Г. Мухаметшин. – Выпуск 6. – Казань: Институт истории АН РТ, 2008. – С. 18.

Шул рәвешле, гарәп язулы кабер ташларының һәрберсен эзләп табып, фотога төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Барлыгы 25(!) борынгы кабер ташы (күбесе фрагментлар) табылды. Эшебезнең нәтиҗәсе буларак, табылган эпиграфик истәлекләрнең тулы текстлары һәм хәзерге татар, рус телләренә тәрҗемәләре игътибарыгызга тәкъдим ителә торган әлеге китапта тулаем чагылды.

Эпитафик текстларны бирүгә килгәндә, шуны әйтәсе килә, ни өчендер галимнәр арасында гарәп җөмләләрендәге саф гарәп сүзләрен татарча әйтелешкә якынлаштырып уку таралаган. Мәсәлән, «ү» хәрефе урынына «ө» куялар, ләкин гарәп телендә «ө» авазы бөтенләй юк бит. Болай язу татар телендәге җөмләләр эчендә булган алынма гарәп сүзләренә генә кагылырга мөмкин. Без башка принцип белән эш итеп, ташлардагы гарәп җөмләләрен тәҗвид кагыйдәләренә туры китерелгән формада язарга булдык. Бу бары тик сузык хәрефләрне (мәдләрне) биргәндә генә шулай эшләнде. Мәсәлән, «зәәикатүн» сүзендә «зәл» хәрефеннән соң «әлиф» тора, шуны белдерер өчен ике «ә» куелды. Әгәр дә шуны белдерер өчен «з» хәрефеннән соң «а» хәрефе куйсак, дөрес булмый, чөнки «з» хәрефе бу очракта нечкә аваз (гарәп телендә «з»ның калын әйтелә торганы да бар) һәм нечкә әйтелергә тиеш. Шулай ук гарәпчә «дөнья» сүзен «дүнйәә» дип бирдек, чөнки «йә» хәрефе гарәпләрдә нечкә әйтелә, ә ике «ә» хәрефен кую «й»дан соң «әлиф» килгәнен белдертә. Шуның кебек үк тартык хәрефләрдән соң гарәп алфавитындагы «йә» хәрефе торса, ике «и» (калын әйтелгәндә «ыый») хәрефе, «уау» хәрефе килсә ике «ү» («у») куйдык. Гарәп теле фонетикасын бозмас өчен болай эшләү дөресрәк һәм отышлырак, дип уйлыйбыз, чөнки ташлардагы язмаларның күбесе гарәп телендә язылган: Коръән аятьләре, хәдисләр, шигырьләр, гыйбарәләр, мәкаль-әйтемнәр һ.б. Коръәнгә килгәндә, ул, ислам дине өйрәтүенчә, бары тик тәҗвид ка-

гыйдәләре буенча гына укылырга тиеш, шуңа күрә аятьләрне тулысынча шуңа нигезләнеп яздык. Коръәннән кала башка гарәп җөмләләрдә, әйткәнебезчә, «мәд» һәм шулай ук «васыл» (сүзләрнең үзара тоташуы, кушылуы, мәсәлән, «каблә әл-мәүүт» урынына «каблəл-мәүүт» һ.б.) кагыйдәләрен кулландык.

Китабыбызда китерелгән ташбилгеләрнең татар телендәге текстларын да хәзерге заман кешесенә аңлавы кыен, чөнки бик күп гарәп-фарсы алынмалары, борынгы төрки сүзләр, архаизмнар һ.б. белән чуарланган. Шуңа күрә халык укысын, аңласын өчен һәр таш текстының хәзерге татар теленә күчермәсе дә бирелде, шактый күп очраган гарәп-фарсы телендәге җөмләләр һәм сүзләр тәрҗемә ителде. Шунысын искәртәбез: борынгы эпитафик текстны хәзерге татар теленә күчергәндә күп очракта юллардагы сүзләр урыннары белән алмашына, шуңа күрә алар тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Мәсәлән, гарәп телендәге җөмләдә фигыль башка сүз төркемнәреннән алда, ә татар телендә ул һәрвакыт артка куела, шул сәбәпле, юлдан юлга тәрҗемә итеп булмый. Иске татар телендә, гарәп теленнән калькалаштыру аркасында, фигыльне җөмлә башына кую очраклары еш күзәтелә, андый очракларда да (тик шигъри юлларга бу кагылмый, чөнки рифмага зыян килүе бар) фигыльне җөмлә ахырына куеп, хәзерге татар теленә күчердек. Барлык эпиграфик истәлекләрнең текстлары рус теленә дә тәрҗемә ителде.

Һиҗри (мөселман) календаренә нигезләнеп бирелгән даталар милади (европача) ел исәбенә күчерелде. Шунысын да бар: ташка язу остасы параллель рәвештә һиҗри һәм милади даталарын язса да, һәрвакыт монда төгәллек булмаган, шуңа күрә бу ике календарь арасында берничә елга, айга яисә көнгә аерма күзәтелергә мөмкин.

Ташларның үлчәмнәре фәндә эпиграфика белгечләре тарафыннан төрлечә бирелә: кайберәүләр башта буен, аннары киңлеген, соңыннан калынлыгын, ә кемнәрдер исә, киресенчә, башта калынлыгын, аннары киңлеген, соңыннан буен күрсәтеп язалар. Без үлчәмнәрне беренче варианттагы тәртиптә бирергә булдык. Мәсәлән, 100х40х10 саннары язылган булса, ташның буе – 100 см, киңлеге – 40 см, калынлыгы – 10 см дигәнне аңлата. Шулай ук кайбер ташбилгеләр махсус нигез өстенә утыртылган, андый очракта гомуми буе җәяләр эчендә күрсәтелде.

# БИШБАЛТА ЗИРАТЫ ТАРИХЫННАН

Бишбалта бистәсе зираты бик борынгы чорларга, ягъни Казан ханлыгы дәверенә үк каравы хакында фикерләр бар, хәтта зиратта, шул турыда искәрткән язмалы бер таш ясатып куелып, анда түбәндәге сүзләр язылган[5]:

1) «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
2) Казан ханлыгы
3) чорының зираты
4) мәдәни ядкәрь
5) историщеское
6) кладбище времен
7) Казанского
8) ханства».

Мәрмәрдән эшләнгән әлеге таш соңгы елларда гына куелганга охшый, аны ташлар һәм цементлы эремә белән ясалган өслек өстенә утыртканнар. Шул рәвешле зиратка игътибарны җәлеп итәргә тырышу бик сөендерә торган гамәл, әлбәттә, әмма «ядкяр» («ядкәр») сүзенең генә хаталы язылуы күңелне бераз борчуга сала.

Тарихи чыганакларда, элекке галимнәр хезмәтләрендә бу тирәдә Казан ханлыгы чорына нисбәтле борынгы кабер ташлары булу турында мәгълүмат очрамый. Хәтта Казан шәһәре һәм аның тирәсендәге борынгы эпиграфик истәлекләрне өйрәнгән галимебез Ш. Мәрҗани Бишбалта бистәсе ташъязмалары хакында бер сүз әйтмәгән, шулай ук XX гасыр башында эпиграфика белән шөгыльләнгән Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Г. Әхмәров, С. Вәхиди һ.б. галимнәр дә бу турыда берни язмаганнар. Без белгән борынгы карталарда Бишбалта бистәсендә татар зираты күрсәтелмәгән, фәкать

[5] Беренче юлы гарәп графикасында, калганнары кириллицада язылган.

XVIII йөзнең ахырына караганнарында гына хәзерге Брюсов урамындагы зират билгеләнгән.

Тарихчы Е.В. Липаков, Бишбалта зиратына 1848 ел декабрендә нигез салынган, чөнки Казан шәһәре Думасы шул елда аны ачарга карар чыгарган, дип язган[6]. Дөрестән дә, архивта сакланган тарихи документларга караганда, шул елда Бишбалта бистәсендә татар һәм рус зиратларына җирләр бүлеп бирү хакында бара, әмма 1793 елга нисбәтле карта[7] нигезендә, XVIII гасырда инде анда татар зираты булган, дип төгәл әйтә алабыз. Шуңа күрә 1848 елгы документта аны зурайту, урынын билгеләү турында сүз барган, чөнки болай диелгән: «*Җир үлчәүче ярдәмчесе Сапожниковка эшчеләр кирәк-яраклары белән астролябия чылбырларын күтәреп йөрү, таяклар кагу, чокырлар казу һәм баганаларны элек билгеләнгән урыннан яңа чик борылышларына күчерү өчен кирәк*»[8]. Бәлки, зират байтак еллар ябылып торып, 1848 елда анда җирләргә рөхсәт итә башлаганнардыр. Ул вакытта зиратның җирләрен билгеләү, үлчәү, казыклар кагу эшләре җир үлчәүче ярдәмчесе Сапожниковка йөкләнгән. Бу эшне башкарып чыгу өчен аңа гласный Командировка мөрәҗәгать итәргә боерылган. Командиров исә ун эшче яллаган һәм үз кесәсеннән кирәкле суммада акча бүлеп биргән. 1849 ел башында эшчеләр буласы зират урыннарында чокырлар казыганнар, таяклар һәм баганалар утыртканнар, астролябия белән җир үлчәргә ярдәм иткәннәр. Шул рәвешле, Сапожников зиратлар өчен кирәк булган

---

[6] Липаков Е.В., Афонина Е.В. История татарских кладбищ: Специальное издание к 1000-летию основания города Казани / Е.В. Липаков, Е.В. Афонина. – Казань, 2005. – С. 46.

[7] Россия дәүләт борынгы актлар архивы: ф. 1354, тасв. 138, I бүлек, сак. бер. М 8.

[8] Татарстан Республикасының Милли архивы: ф. 114, тасв. 1, сак. бер. 2029. – Б. 3–3 арты.

барлык эшләрне тиешле дәрәҗәдә үтәп чыккан. Ахырдан шәһәр бюджетыннан гласный Командировка тотылган акчаларын кире кайтарганнар. Шулай итеп, татар зиратының яңа чикләре билгеләнгән, ә рус зираты Игумново бистәсе янында барлыкка килгән.

1875 елда зиратның попечителе итеп галим Галимҗан Барудиның газиз атасы Мөхәммәдҗан Ибнеямин улы Галиев билгеләнгән[9]. Каберстан су янында урнашканлыктан, яз саен аны өлешчә су баса торган булган, шуңа күрә 1879 елда Шәһәр думасының санитар комиссиясе зиратны ябарга, дигән тәкъдим белән чыккан. 1884 елда Макарьев чиркәве башлыгы Сычов та бу мәсьәләне күтәреп, зиратка мәетләр җирләүне туктату ягында торган. Әмма Мөхәммәдҗан Баруди тырышлыгы белән генә ул ябылмыйча калган, шулай да шәһәр түрәләре мәетләрне яхшылап һәм тирәнрәк күмү шарты куйган булган[10]. Су басу аркасында, үлгәннәрне анда җирләргә тырышмаганнардыр, шуңа күрә 1881 елда да әлеге зират кечкенә генә урын биләгән[11].

Безнең уйлавыбызча, Бишбалта бистәсендә сакланган татар зираты XVIII йөздә барлыкка килгән булса кирәк. Казан ханлыгы чорыннан ук мәгълүм булган бистәдә, әлбәттә, шул борынгы дәвергә караган зират та булмыйча калмагандыр. Бәлки, анысы Бишбалтаның төп урынында, ягъни хәзерге «Петрушкин двор» тирәсендәрәк урнашкандыр. Һәрхәлдә, Брюсов урамындагы зиратта Казан ханлыгы чорына

[9] Липаков Е.В., Афонина Е.В. История татарских кладбищ: Специальное издание к 1000-летию основания города Казани / Е.В. Липаков, Е.В. Афонина. – Казань, 2005. – С. 46–47.

[10] Шунда ук. – С. 48–49.

[11] История Казани в документах и материалах. XIX век. Книга III: Управление, бюджет, хозяйство / Под ред. И.К. Загидуллина. – Казань: Главное архивное управление при КМ РТ, 2011. – С. 48.

түгел, хәтта XVIII йөзгә нисбәтле эпиграфик истәлекләр дә сакланмаган.

Зиратка Бишбалтада яшәүче татарларны, шул тирәдәге предприятиеләрдә һәм якындагы сәүдә пристанендә эшләүчеләрне, бистә сырхауханәсендә вафат булган мөселманнарны җирләгәннәр. Шулай да Бишбалта бистәсендә яшәүче татарларның барысын да шундагы зиратка гына җирләмәгәннәр, кайберләре Яңа татар бистәсе һ.б. зиратларга күмелгән.

# БИСТӘДӘ ТАБЫЛГАН КАБЕР ТАШЛАРЫ

## 1. Билгесез кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) рахимәһәәллааһү[12] Тәгааләә
2) рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте
2) белән рәхим кылсын».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
«...
1) Пусть Всевышний Аллах помилует его
2) обширной милостью».

Таш үлчәмнәре: 38x27x10.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 57, № 1.*

[12] Фигыль кушымчасы әлеге ташның хатын-кызга куелганлыгын күрсәтә.

**2. Билгесез кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) Аллаһ рәхмәт кылсун».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
«...
1) Пусть Аллах помилует».

Таш үлчәмнәре: 14(35)х31х15.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 57, № 2.*

**3. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
«...
1) дарел-фәнадан дарел-бәкайә рихләт [кылды]
2) гарикы рәхмәт улсун».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әй бәңа зийәрәт кыйлгучы...

Сул ягы (калкытып язылган): «... кыйлуңыз шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.
2) Рәхмәткә күмелсен».

Уң ягы: «Әй, мине зиярәт кылучы...

Сул ягы: «... [рухымны] шатландырыгыз».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
«...
1) из мира бренности в мир вечности переселился.
2) Пусть будет милость над ним».

Правая сторона: «Эй, посетивший меня...

Левая сторона: «... обрадуйте [мою душу]».

Таш үлчәмнәре: 106x33x10.

Үзенең тышкы кыяфәте һәм палеографик билгеләре буенча әлеге таш һичшиксез XIX гасыр урталарына туры килә һәм зиратта сакланган иң борынгы эпиграфик истәлек булып саналырга хаклы. Кызганычка каршы, җимерелү сәбәпле, текстына зур зыян килгән.

Таш үлчәмнәре: 60x34x17.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 57, № 3.*

**4. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «... [салләәллааһү] галәйһи вә сәлләм
2) шәһре мөхәррәм 26
...».

Сул ягы (уеп язылган): «... [са]гышлайасыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен.
2) 26 мөхәррәм аенда
...».

Сул ягы: «... [са]гышланыгыз».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
1) «Пусть Аллаһ благословит его и приветствует.
2) 26 числа месяца мухаррам
...».

Левая сторона: «... печальтесь».

Таш үлчәмнәре: 37х21х18.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 58, № 4.*

**5. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Тарих...
...».

Перевод на русский язык

1) «По летоисчислению...
...».

Таш үлчәмнәре: 27x26x17.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 58, № 5.*

**6. Билгесез кабер ташы фрагменты, 1915 ел.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) 80 йәшендә 1333 сәнәи
2) зөлкагдә 22 ндә
3) 1915 сәнәи румиййә  синтәбр 18 ндә
4) мәдфүн рахимәһүллааһү[13]
5) Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «... [рау]датән мин рийәәдыйль-җәннәһ».

[13] Фигыль кушымчасы әлеге ташның ир-атка куелганлыгын күрсәтә.

Сул ягы (уеп язылган): «Үзкүрүү мәхәәсинә мәүтәәкүм [вә күффүү гань мәсәәвииһим]».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

«...

1) 80 яшендә [һиҗри] 1333 елның
2) 22 зөлкагдәсендә,
3) милади 1915 елның 18 сентябрендә
4) җирләнде. Аллаһ Тәгалә аны киң
5) рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «[Аллаһ аның каберен] җәннәт бакчаларыннан бер бакча [итсен]».

Сул ягы: «Мәетләрегезнең яхшы якларын искә алыгыз, [начарлыкларын телгә алмагыз]».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:

«...

1) в возрасте 80 лет в 1333 году [по хиджре]
2) 22 числа месяца зулька‘да,
3) 18 сентября 1915 года
4) был похоронен. Пусть Всевышний Аллах
5) помилует его обширной милостью».

Правая сторона: «[Пусть Аллах сделает его могилу] садом из садов рая».

Левая сторона: «Упоминайте положительные качества ваших покойных, [воздержитесь от упоминания их недостатков]».

Таш үлчәмнәре: 65x34x15.

Әлеге кабер иясенең исеме Нигъмәтулла булырга мөмкин, чөнки метрикә кенәгәләрендә Бишбалтада 18 сентябрьдә 80 яшьтә нәкъ менә шул кешенең вафат булуы күрсәтелгән. Аның атасы Казан мещаны Гыйззәтулла Гайсә улы Габбасов икәнлеге дә язылган[14].

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 58, № 6.*

**7. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) шинбә көн каберен җәннәт бакчасы
2) улгай амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) шимбә көн [вафат яки җирләнде]. Кабере җәннәт бакчасы
2) булсын, амин».

[14] Татарстан Республикасының Милли архивы: ф. 204, тасв. 180, сак. бер. 24. – Б. 307.

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:

«...

1) в субботу [скончался(ась) или был(а) похоронен(а)]. Пусть его могила будет

2) садом рая, аминь».

Таш үлчәмнәре: 27(53)х36х16.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 58, № 7.*

**8. Мулла Билаледдин Габид улына куелган кабер ташы, 1918 ел.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Әш-шәйху
2) мулла Билаледдин
3) әл-Габиди әл-Бохари
4) 48 сәнә имамәт итеб
5) 80 йәшендә
6) 1336 сәнәи һиҗриййә мөхәррәм 19 нда
7) 1918 сәнәи миладиййә үктәбр 14
8) мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган):

1) «Рахимәһүллааһү Тәгааләә
2) рахмәтән вәәсигаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү мәркадәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Шәех
2) мулла Билаледдин
3) Габиди Бохари,
4) 48 ел имамлык итеп,
5) 80 яшендә
6) һиҗри 1336 елның 19 мөхәррәмендә,
7) милади 1918 елның 14 октябрендә
8) җирләнде».

Уң ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте
2) белән рәхим кылсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
1) «Шейх
2) мулла Билалуддин
3) ал-Габиди ал-Бухари
4) (48 лет был имамом)
5) в возрасте 80 лет
6) в 1336 году по хиджре 19 числа месяца мухаррам,
7) 14 октября 1918 года
8) был похоронен».

Правая сторона:
1) «Пусть Всевышний Аллах помилует его
2) обширной милостью».

Левая сторона: «Пусть Аллах озарит его могилу».

Таш үлчәмнәре: 122х42х30.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 59, №№ 8, 8а.*

**9. Билгесез ир-атка куелган кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) ...нда
2) вафат
3) рахимәһүллаађү[15] Тәгааләә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) ...нда
2) вафат.
3) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
«...
1) в ...
2) скончался.
3) Пусть Всевышний Аллах помилует его».

[15] Фигыль кушымчасы әлеге ташның ир-атка куелганлыгын күрсәтә.

Таш үлчәмнәре: 44(73)x41x18.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 59, № 9.*

**10. Билгесез кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

«...

1) мәдфүн Аллаһ
2) рәхмәт кыйлсун
3) әнкәсендән йәдкәр[16]».

Уң ягы (уеп язылган): «Хафалардан җәфалардан...».

Сул ягы (уеп язылган): «... кайим булсун олуг кадерең».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

«...

1) җирләнде. Аллаһ
2) рәхим кылсын.
3) Әнкәсеннән ядкяр».

Уң ягы: «Хафалардан, җәфалардан...».

Сул ягы: «... торсын олуг кадерең».

---

[16] Димәк, бу – яшь балага куелган таш.

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:

«...

1) был(а) похоронен(а). Пусть Аллах
2) помилует.
3) Памятник от матери».

Правая сторона: «От горя, печалей...».

Левая сторона: «... пусть будет глубокое почитание».

Таш үлчәмнәре: 28x33x13.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 59, № 10.*

**11. Билгесез кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

«...

1) –әбр 12 ндә вафат
2) Аллаһ рәхмәт
3) кыйлсун».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:

«...

1) 12 ...бря скончался(ась).
2) Пусть Аллах
3) помилует».

Таш үлчәмнәре: 23х32х15.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 60, № 11.*

**12. Сөләймановка куелган кабер ташы фрагменты, 1911 ел.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) Сөләйманыф 82 йәшендә [1329] сәнәи һиҗриййә
2) рабигыль-ахир 12 ндә 1911 нч сәнәи румиййә март 29 нда
3) сиһшәнбә көн кабере раудатүн мин рийәәдыйль-җәннәһ
4) ... амин забир Шакир мөәзин».

Уң ягы (уеп язылган): «[Галә]мәтдин морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «[Бу көн бәңа икән] йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) Сөләйманов 82 яшендә һиҗри [1329] елның
2) 12 рабигыль-ахирендә, милади 1911 елның 29 мартында

3) сишәмбе көн [вафат яки җирләнде]. Кабере җәннәт бакчаларыннан бер бакча

4) [булсын], амин. Язучы: Шакир мөәзин».

Уң ягы (уеп язылган): «[Галә]мәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «[Бу көн миңа икән], иртәгә сиңадыр».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:

«...

1) Сөләйманов в возрасте 82 года [в 1329] году по хиджре

2) 12 числа месяца раби‘ ал-ахир, 29 марта 1911 года

3) во вторник [скончался или был похоронен]. Пусть будет его могила садом из

4) садов рая, аминь. Мастер-резчик: муадзин Шакир».

Правая сторона: «Цель от памятника – молитва [чтобы помолились за меня]».

Левая сторона: «[Сегодня для меня [установлен памятник],] завтра для тебя [установят]».

Таш үлчәмнәре: 68х35х18.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 60, № 12.*

## 13. Билгесез ир-атка куелган кабер ташы фрагменты, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) Мәмдәл[17] авылының
2) 31 йәшендә
3) 1922 сәнә үктәбр
4) 10 нда вафат
5) Аллаһ рәхмәт
6) кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Гафәра[ллааһү зүнүүбәһ]».

Сул ягы (уеп язылган): «[Нәүвәра]ллааһү мәркадәһ[18]».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) Мәмдәл авылыннан
2) 31 яшендә
3) 1922 елның 10
4) октябрендә вафат.
5) Аллаһ рәхим
6) кылсын».

Уң ягы: «[Аллаһ аның гөнаһларын] гафу итсен».

---

[17] Хәзерге Биектау районына кергән авыл.

[18] Бу сүзгә ир-атка карата кулланыла торган кушымча ялганган, шуңа күрә таш ир-атка куелган, дип саныйбыз.

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен [нурландырсын]».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
«...
1) (из села Мемдель)
2) в возрасте 31 года
3) 10 октября 1922
4) года скончался.
5) Пусть Аллах
6) помилует».

Правая сторона: «[Пусть Аллах] простит [ему грехи]».

Левая сторона: «Пусть Аллах [озарит] его могилу».

Таш үлчәмнәре: 78х30х20.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 60, № 13.*

**14. Билгесез кабер ташы, XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
...».

Уң ягы (уеп язылган): «Гафәраллааһү зүнүүбәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү мәркадәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
...».

Уң ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
1) «Смерть – поучительный пример.
...».

Правая сторона: «Пусть Аллах простит ему грехи».

Левая сторона: «Пусть Аллах озарит его могилу».

Таш үлчәмнәре: 80х53х23.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 60, № 14.*

**15. Билгесез кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
...».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
1) «Решение у Аллаха.
...».

Таш үлчәмнәре: 19х32х15.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 61, № 15.*

**16. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) [рахимәһү]ллааһү
2) рахмәтән вәәсигаһ
3) әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) Аллаһ аны киң рәхмәте
2) белән рәхим кылсын,
3) амин».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
«...
1) Пусть Аллах помилует его
2) обширной милостью,
3) аминь».

Таш үлчәмнәре: 28х33х12.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 61, № 16.*

**17. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) ...5 йәшендә вафат табды гар...».

Уң ягы (уеп язылган): «...лайасыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) ...5 яшендә вафат булды».

Уң ягы: «... [багыш]лагыз».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:

«...
1) ...в возрасте ...5 лет скончался(ась)».

Правая сторона: «... [посвя]щайте».

Таш үлчәмнәре: 27(51)x34x15.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 61, № 17.*

**18. Билгесез кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
...».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Гафәра
2) зүнүүбәһ
3) әәмиин».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «[Рахимә]һүллааһү
2) [Тәгаа]ләә рахмәтән
3) вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
...».

Уң ягы:
1) «[Аллаһ] аның гөнаһларын
2) гафу итсен,
3) амин».

Сул ягы:
1) «Аллаһ [Тәга]лә аны
2) киң рәхмәте
3) белән [рәхим кылсын]».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
1) «Смерть – поучительный пример.
...».

Правая сторона:
1) «Пусть [Аллах] простит
2) ему грехи,
3) аминь».

Левая сторона:
1) «Пусть [Всевыш]ний Аллах [простит]
2) его обширной
3) милостью».

Таш үлчәмнәре: 75x57x20.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 61, № 18.*

## 19. Әсхабҗамал Йосыф кызына куелган кабер ташы фрагменты, XIX гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) көн мөтәвәффийиә Әсхабҗамал
2) Йосыф кызы Мотыйгулла хәлә-
3) –ле 36 йәшендә рух пөрфөтухы
4) тарафе гыйләллинә пәрвәз әйләде нәүвәраллааһ».

Уң ягы (уеп язылган): «... әүләд гакыйл кәрәм әйләб безә дайим дога кыйл».

Сул ягы (уеп язылган): «[Галәмәт]дән морадым бер догадур бу көн бәңа икән йарин сәңадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) көн вафат булучы Әсхабҗамал
2) Йосыф кызы – Мотыйгулла хәлә-
3) –ле – 36 яшендә аның юмарт рухы
4) килеп чыгу тарафына очты. Аллаһ нурландырсын».

Уң ягы: «... акыллы балалар, юмартлык кылып, безгә даими дога кыл[ыгыз]».

Сул ягы: «[Галәмәт]тән морадым бер догадыр; бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:

«...

1) умершая Асхабджамал
2) дочь Юсуфа – жена Мутыйгул-
3) –лы в возрасте 36 лет, её щедрая душа
4) улетела в сторону истока. Пусть Аллах озарит».

Правая сторона: «... разумные дети, будучи щедрыми, постоянно молитесь за нас».

Левая сторона: «Цель от [памятника] – молитва [чтобы помолились за меня]. Сегодня для меня [установлен памятник], завтра для тебя [установят]».

Таш үлчәмнәре: 87x34x18.

Үзенең тышкы кыяфәте һәм палеографик билгеләре буенча әлеге таш XIX гасырның 70 нче елларына туры килә һәм зиратта сакланган иң борынгы эпиграфик истәлекләрнең берсе булып саналырга хаклы.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 62, № 19.*

**20. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

«...

1) рәҗәб 6 нда 17 йәшендә

2) вафат
3) Аллаһ рәхмәт кыйлсун
4) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «...мәк йәүме мәхшәр җитмичә».

Сул ягы (уеп язылган): «Йат тынычлаб мәркадеңдә ка...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) 6 рәҗәбендә 17 яшендә
2) вафат.
3) Аллаһ рәхим кылсын,
4) амин».

Уң ягы: «[Юк инде безгә күреш]ү кыямәт көне җитмичә».

Сул ягы: «Йат тынычлап кабереңдә, ка[йгы гамьнәр чикмичә]».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
«...
1) 6 числа месяца раджаб в возрасте 17 лет
2) скончался(ась).
3) Пусть Аллах помилует,
4) аминь».

Правая сторона: «[Не сможем уже встретиться,] пока не настанет Судный день».

Левая сторона: «Находись [спи] спокойно в своей могиле, не [зная бед и печали]».

Таш үлчәмнәре: 40х33х12.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 62, № 20.*

**21. Гыймрановага куелган кабер ташы фрагменты, 1910 ел.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) Гыймраниййә
2) 4 нче йәшендә
3) 1339[19] сәнә һиҗриййә
4) рәҗәб 27 ндә
5) вафат шәфәгатьче
6) улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «1910 сәнә румиййә април...».

Сул ягы (уеп язылган): «... бакчасы булсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

---

[19] Хата киткән булса кирәк, чөнки һиҗри 1339 ел милади 1921 елга туры килә, ләкин ташның кырыенда милади 1910 ел күрсәтелгән.

«...
1) Гыймранова
2) 4 нче яшендә
3) һиҗри 1339 елның
4) 27 рәҗәбендә
5) вафат. Шәфәгатьче
6) булсын».

Уң ягы (уеп язылган): «Милади 1910 елның апрелендә...».

Сул ягы: «[Кабере җәннәт] бакчасы булсын».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
«...
1) Гимранова
2) на 4-ом году жизни
3) в 1339 году по хиджре
4) 27 числа месяца раджаб
5) скончалась. Пусть будет
6) заступником [за родителей]».

Правая сторона: «В апреле 1910 года...».

Левая сторона: «Пусть [его могила] будет садом [рая]».

Таш үлчәмнәре: 60x33x17.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 62, № 21.*

**22. Мөхәммәдвазыйх Гыйльман улына куелган кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Мөхәммәдвазыйх
3) Гыйльман углы
...».

Уң ягы (уеп язылган): «... рәҗәб».

Сул ягы (уеп язылган): «...дә април».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мөхәммәдвазыйх
3) Гыйльман улы
...».

Уң ягы: «... рәҗәб [аенда вафат]».

Сул ягы: «...апрельдә [вафат]».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
1) «Решение у Аллаха.
2) Мухаммадвазих
3) сын Гильмана
...».

Правая сторона: «... месяца раджаб».

Левая сторона: «... апреля [скончался]».

Таш үлчәмнәре: 46х34х16.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 62, № 22.*

**23. Гайшәбикә Сәгъди кызына һәм Рилия Харис кызына куелган кабер ташы, 1933 ел һәм XX гасырның икенче чиреге.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган[20]):
1) «Гайшәбикә
2) Сәгъди кызы
3) вафат Аллаһ рәхмәт кылсын
4) Гайшәбикә
5) Сәгъди кызы
6) ту...
7) в. 1933, 19/XII».

Арткы ягы (уеп язылган[21]):
1) «Рилийә
2) Харис кызы
3) Рилийә
4) Хар...
5) ...».

---

[20] Ахыргы дүрт юлы латин графикасында язылган. Ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.

[21] Өченче юлдан башлап аска таба латин графикасында язылган. Ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.

## Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Гайшәбикә
2) Сәгъди кызы
3) вафат. Аллаһ рәхим кылсын.
4) Гайшәбикә
5) Сәгъди кызы
6) ... [елда туган],
7) 1933 [елның] 19 декабрендә вафат».

Арткы ягы:
1) «Рилия
2) Харис кызы.
3) Рилия
4) Хар[ис кызы]
5) ...».

## Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
1) «Гайшабика
2) дочь Сагди
3) скончалась. Пусть Аллах помилует.
4) Гайшабика
5) дочь Сагди
6) ро[дилась в]...,
7) скончалась 19 декабря 1933 [года]».

Оборотная сторона:
1) «Рилия
2) дочь Хариса.
3) Рилия

4) [дочь] Хар[иса]
5) ...».

Таш үлчәмнәре: 89(104)х30х13.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 63, №№ 23, 23а.*

**24. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) ... 76 йәшендә даре бәкайә
2) рихләт әйләде рахимәһүллааһү рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтд...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) ... 76 яшендә мәңгелек дөньяга
2) күчте. Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Сул ягы: «Галәмәтт[ән морадым бер догадыр]».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:

«...

1) ... в возрасте 76 лет в дом вечности

2) переселилась. Пусть Аллах помилует его обширной милостью, аминь».

Левая сторона: «[Цель] от памятника – [молитва [чтобы помолились за меня]]».

Таш үлчәмнәре: 32(65)x36x18.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 63, № 24.*

**25. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

«...

1) ... сәнә 63 йәшендә мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйл[әб догада идеңез йад]».

Сул ягы (уеп язылган): «[Тәсаддыклә кыйлыгыз рухым]ы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

«...
1) ...елда 63 яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, [догада искә алыгыз]».

Сул ягы: «[Сәдака бирү белән рухымны] шатландырыгыз».

Перевод на русский язык

Лицевая сторона:
«...
1) ... году в возрасте 63 года был(а) похоронен(а)».

Правая сторона: «Будучи щедрыми, [вспомните про нас в молитвах]».

Левая сторона: «Обрадуйте [мою душу, дав за меня милостыню]».

Таш үлчәмнәре: 30(59)x31x13.

*Китапның кушымтада фотосын кара: б. 63, № 25.*

# ЙОМГАК

Күргәнебезчә, Бишбалта бистәсе зиратында иң борынгы ташлар эшләнеше һәм палеографик билгеләре буенча XIX гасыр урталарына карый, аларның да, ватылу сәбәпле, күбесенең текстларына зыян килгәнгә күрә, төгәл куелу вакытын, ягъни елын ачыклап булмый. Датасы язылган ташлар арасында иң борынгысы 1910 елның апрель аена карый. Кызганычка каршы, кемгә куелганлыгы билгесез, чөнки аның өске өлеше – исеме язылган урыны – ватылып төшкән. Шунысы аңлашылмый: ташның уң ягында «1910 ел» дип язылса да, алгы ягында «һиҗри 1339 елның 27 рәҗәбе» дип язылган. Әлбәттә, монда ялгышлык киткән, чөнки миләди 1910 ел һиҗри 1329 елга туры килә. Ташка язу остасының хаталануы – сирәк булса да, очрый торган күренеш. Иң соңгы куелган кабер ташы 1933 елга карый, ул Гайшәбикә Сәгъди кызына һәм Рилия Харис кызына куелган. Бу елларда гамәлдә латин язуы булганга, әлеге ташъязма истәлек яртылаш гарәп, яртылаш латин графикасында язылган. Халык сөйләвенә караганда, Бишбалта зиратына XX йөзнең 50 нче елларында да мәетләрне җирләгәннәр. Мәсәлән, Х. Баһаветдинова сөйләвенчә, аның бабасы 1950 елда биредә күмелеп, кабере өстенә таш та куелган булган, әмма Куйбышев сусаклагычы барлыкка килү аркасында аның җирләнгән урыны елга төбендә калган. Шул сәбәпле, зиратның байтак өлеше су астында калып, күпме эпиграфик истәлекләрнең әрәм булуына көенергә генә кала. Бәлки, киләчәктә Бишбалта зиратына тиешлечә игътибар бирелсә, зиратның шул өлеше дә галимнәр тарафыннан өйрәнелер.

Бүгенге көндә зиратта фәкать бер генә эпиграфик истәлек күпмедер дәрәҗәдә бөтен килеш сакланып калган,

чөнки ул нык материалдан, төгәлрәк әйткәндә, көрән гранит-тан эшләнгән. Югары зәвык белән ясалган әлеге мәһабәт таш мулла Билаледдин Габид улына куелган. Әлеге кабер иясе 1841 елның 20 маенда Тәтеш өязе Олы Яңасала волосте (хәзерге Кама Тамагы районы) Иске Казиле (Суыксу) авылында дөньяга килгән[22]. Ташындагы 80 яшь дигәне һиҗри ел исәбе белән билгеләнгән, һиҗри ел бераз кыскарак булганга күрә, вафат булганда милади ел исәбе белән аңа 77 яшь булган. Билаледдин хәзрәт Казандагы Хәммад Халиди мәдрәсәсендә гыйлем туплап, 1874 елның 3 маенда указ (№ 3143) алганнан соң[23], Бишбалта бистәсе мәчетендә ярты гасырга якын, ягъни 1918 елга кадәр имам-хатыйб һәм мөдәррис вазыйфаларын башкарган. Метрика кенәгәсендә аның атасы Габид Ягъкуб улы буларак ялгыш күрсәтелеп, шул ук Суыксу авылында казыйлык һәм муллалык вазыйфаларын башкарганлыгы язылган[24]. Галим Ризаэтдин Фәхретдин исә аны Габид бине Минкә бине Ягъкуб дип биргән, ягъни Ягъкуб Билаледдин хәзрәтнең бабасы түгел, ә бабасының атасы булып чыга: «Габид бине Минкә бине Ягъкуб Тәтеш өязе Суыксу авылында имам булып, 1281 (1864) елның рабигыль-әүвәл аенда (2 август) 81 яшендә вафат булды. Җәмгыяте шәргыйдә никадәр вакыттыр әгъза булып торды. Остазы Юртыш авылыннан Хәмид бине Ислам иде. Билал, Габдессаттар, Мөхәммәдвафа исемле уллары калды. Билал бүген Казан шәһәрендә Бишбалта мәхәлләсендә, Мөхәммәдвафа исә Суыксу авылында имамнар»[25].

---

[22] Салихов Р.Р., Измайлов Б.И. Адмиралтейская слобода / Р.Р. Салихов, Б.И. Измайлов. – Пенза: ИП Рогожин И.В., 2013. – С. 84.

[23] Татарстан Республикасының Милли архивы: ф. 2, тасв. 2, сак. бер. 524. – Б. 32–33.

[24] Шунда ук. – ф. 204, тасв. 180, сак. бер. 66. – Б. 109 арты.

[25] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 99.

1762 һәм 1834 елгы ревизияләр нигезендә без Билаледдин мулланың шәҗәрәсен ачыкладык: Билаледдин бине Габид (1785 елда туган) бине Минкә (1768 елгы) бине Ягъкуб (1724 елда туган) бине Малидәр (1703 елгы) бине Нәказин (1672 елда туган)[26]. Хәзрәтнең улы Исмәгыйль дә, Казандагы Хәммад хәзрәт Халиди мәдрәсәсендә укып, 1914 елның 20 гыйнварында указ (№ 428) алганнан соң, атасы хезмәт куйган мәчеткә мулла итеп билгеләнгән[27]. Исмәгыйль хәзрәт киң карашлы мөгаллим, шулай ук шагыйрь буларак билгеле, аның кайбер әсәрләре хәзерге көнгә хәтле сакланып калган. Ул Урта Азия якларында кадимчелеккә каршы көрәшү, халыкны агарту, схоластикадан арындыру эшендә бик күп хезмәт куйган. Исмәгыйль хәзрәт үзенең бер хатында ата-анасына түбәндәге сүзләр язган: «Көч һәм җаныбыздан килгән кадәр куәт белән эштә дәвам итәбез. Ләкин тарихы олуг булса да, бу көнге көн тәмам бетү һәм хараплыкка төшкән Төркестан милләтен адәм рәтле бер юлга салу бик мөшкел. Өмет аз! Бохарада җәдидләрне үтерергә дип карар чыгарганнар, Әндиҗанда чалма кимәүчеләр мөселман түгел, дип фәтва язганнар, Ташкентта голәмага «сез» диясе урында «син» диючеләр – үзе кяфер, хатыны талак була, дип бердәм карар иткәннәр һәм башкалар... Уйлагыз, менә шул халык арасында ничек эшләргә, ничек ислахның чарасын күрергә мөмкин? Ләкин үзебез өметсез булмыйбыз. Эшлибез, тырышабыз. Кайчак куркыту һәм янау булса да, тоткан юлыбыздан, мөкаддәс планыбыздан

[26] Россия дәүләт борынгы актлар архивы: ф. 350, тасв. 1, сак. бер. 2999. – Б. 182 арты–183; Татарстан Республикасының Милли архивы: ф. 3, тасв. 2, сак. бер. 102. – Б. 198 арты.

[27] Татарстан Республикасының Милли архивы: ф. 204, тасв. 180, сак. бер. 24. – Б. 273 арты.

аерылмыйбыз!»[28] Ул татар халкына гына түгел, хәтта башка төрки халыкларга да зур файда китергән. Билаледдин хәзрәт улының җәдидчелек хәрәкәтендә шулай актив катнашуына бер дә каршылык күрсәтмәгән, киресенчә, аңа һәрвакыт таяныч, терәк булган. Шундый акыллы, фидакарь, олуг шәхес тәрбияләп үстерә алган Билаледдин хәзрәтнең үзен дә һичшиксез чын җәдидче итеп санарга мөмкин. Официаль документларда әлеге мулланың мәдрәсәсе кадими буларак күрсәтелсә дә, чынлыкта, анда җәдидчелек һәм дини реформаторлык рухында укытканнар[29]. Кабер ташында ул «шәех» дип күрсәтелсә дә, Билаледдин хәзрәтнең суфичылык сектасы белән бернинди бәйләнеше юк, бу – олылау йөзеннән әйтелә торган сүз.

Югарыда искә алынган шәхескә куелган кабер ташыннан тыш, Әсхабҗамал Йосыф кызы, Мөхәммәдвазыйх Гыйльман улы, Гайшәбикә Сәгъди кызы, Рилия Харис кызы, Гыймранова, Сөләймановларга куелган эпиграфик истәлекләрне табу бәхетенә ирештек. Тиешле дәрәҗәдә эпиграфик тикшеренүләр уздырмаганга, моңарчы әле, Бишбалта зиратында Билаледдин Габид улына куелган бердәнбер таш кына сакланган, дип уйлыйлар иде. Без исә тагын алты кешенең исемнәрен яки фамилияләрен ачыклый алдык һәм 25(!) кабер ташы таба алдык.

Эш барышында Шакир исемле ташка язу остасы исеме ачыкланды. Ул ташбилгегә матур каллиграфик стиль белән язган һәм эше һичшиксез игътибарга лаек. Кызганычка каршы, бу оста турында бүтән мәгълүмат юк, фәкать мөәзин булганлыгы гына мәгълүм. Бәлки, әлеге шәхес Бишбалта бистәсе мәчетендә 1907 елдан башлап мөәзин вазыйфа-

---

[28] ТР ФА ТӘҺСИнең Язма һәм Музыкаль мирас үзәге: ф. 53, тасв. 5, сак. бер. 13. – Б. 24 арты.

[29] Салихов Р.Р., Измайлов Б.И. Адмиралтейская слобода / Р.Р. Салихов, Б.И. Измайлов. – Пенза: ИП Рогожин И.В., 2013. – С. 88.

сын үтәгән Шакир Мирхәйдәров булгандыр. Ул исә 1873 елның 6 ноябрендә дөньяга килгән, чыгышы белән Самара губернасы Ставрополь өязе Мусеевка авылыннан; Казанның Апанай мәдрәсәсендә гыйлем туплап, 1907 елның 10 июлендә указ алган[30].

Шулай ук тышкы сыйфатлары һәм текстлары белән кайсыдыр ташка язу остасы эше икәненә ишарә итеп торучы ташъязма истәлекләр дә бар, тик аларда язучы-оста үзенең исемен теркәп калдырмаганга, моны нәкъ менә шул кеше язган, дип төгәл әйтеп булмый. Бер үк калып һәм стиль белән эшләүче һәм бер дәвердә яшәүче каллиграфлар да юк түгел. Кызганычка каршы, күпләре үзләренең эшләрендә исемнәрен теркәп куюны кирәк дип санамаган. Беренчедән, татар халкы электән үк тыйнак булган һәм эшләре белән мактануны сөймәгән, икенчедән, кабер ташына вафат булучы исеме белән беррәттән, үз исемеңне дә язу, төрле ышанулар, хорафатлар белән бәйле булып, ничектер, үз үлемеңне дә чакыру кебек тоелгандыр. Ташка язу, бизәк төшерү процессы гаять катлаулы булган, остадан күп көч, тырышлык, сабырлык, сәләт сораган. Материал, гадәттә, җир астыннан чыгарылгач та, дымлы көенчә булганда җиңел эшкәртелгәнгә күрә, аңа язу өчен яңа чыккан ташларны сайлаганнар. Ә инде кибеп каткач, анда язу төшерү, әлбәттә, авыррак булган. Аларны «еш очракта ике метр озынлыктагы зур пычкы белән дүрткел формада кискәннәр, балта белән эшкәрткәннәр, каләм белән язганнар һәм махсус өтергеләр ярдәмендә уеп бизәк төшергәннәр. Әгәр дә эш барышында таш кибеп катыланып китсә, язарга уңайсыз була башласа, аны берникадәр вакыт су эченә салып тот-

---

[30] Салихов Р.Р., Измайлов Б.И. Адмиралтейская слобода / Р.Р. Салихов, Б.И. Измайлов. – Пенза: ИП Рогожин И.В., 2013. – С. 88.

каннар яисә өстенә су сибеп торганнар һәм шундый рәвештә ташны йомшартып әүвәлге хәленә кайтарганнар»[31].

Ничә тапкыр халык тарафыннан җыештырылса да, зиратны гел чүп-чар баса, ниләр генә булмый анда: пластик шешәләр, кәгазьләр, целлофан пакетлар, шәхси гигиена әйберләре, кулланылган шприцлар һ.б. Кызганычка каршы, бөтен ташлар диярлек ватылган, җимерелгән, аударылган. Шунысын да әйтергә кирәк: зиратның бөтен җирендә таш ватыклары ауналып ята, әмма аларның барысы да кабер ташлары түгел. Беренчедән, чагыштырмача кечкенә генә урында шуның хәтле күп кабер ташлары була алмый, икенчедән, аларның материал үзенчәлекләре башкача. Ул ташлар кайдан чыккандыр – аңлашылмый, бәлки, алар төрбә яисә кайчандыр зиратны әйләндереп алынган таш койма калдыкларыдыр.

Шушы китапны укыганнан соң байтак кеше, зиратка барып, догалар кылырлар, кабер ташларын төзәтеп, тәртипкә китереп, зиратны җыештырып кайтырлар, дип ышанабыз. Тик шунысын онытмаска кирәк: кабер ияләрен изгеләштереп, алардан нәрсәдер сорау, ялвару, бәрәкәт эзләү, каберләре янында корбаннар чалу, табыну урыны ясау – илам дине өйрәтүенчә, гөнаһлы гамәлләр. Бу турыда кисәткән иң олуг дин галимнәребезнең берсе Ризаэддин Фәхреддиннең түбәндәге сүзләрен китерергә мөмкин: «Зиярәт кылган вакытта мәет һәм мәетләр өчен дога кылу да тиешле эш. Рәсүлүллаһ һәм сәхабәләре каберлекләрдә мәетләр өчен догалар кылалар иде. Әмма үлекләрдән ярдәм сорау, аларга сыену, алардан хәҗәт сорау өчен каберлекләргә бару дөрес түгел, бәлки, ислам шәригатендә тыелган

[31] Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр / В.М. Усманов. – Уфа: ДизайнПолиграфСервис, 2005. – Б. 55–56.

бер эштер»[32]. «Каберләрдән һәм шәехләрдән ярдәм сорау гадәте әүвәлге мөселманнарда юк иде. Ислам дөньясына моны надан суфилар чыгардылар, халыклар арасына яхшы бер эш итеп күрсәттеләр»[33].

Шулай ук безнең бөек дин галимебез Галимҗан Барудиның да хикмәтле сүзләрен җиткерү артык булмас: «Нәтиҗә: зияраттән беренче максат – үлемне искә төшерү, моның белән үзеңне төзәтеп, ахирәткә әзерләнү. Үлемне бервакытта да истән чыгару дөрес булмаса да, дөнья шөгыльләре сәбәпле, күбесенчә үлемнән гафләт ителә. Каберләргә зиярәт исә бу гафләт китүгә, үлем искә төшүгә сәбәп була. Сөннәт булган зиярәт – бу рәвештәге зиярәт. Башка рәвештәге зиярәт, мәсәлән, «әүлия каберләре» дип билгеле булган каберләргә сәдакалар бирү (Шәһри Болгар һәм Хуҗалар тавы ише зиратларына барып, корбаннар чалу кебек), корбаннар чалу, алардан ярдәм сорау, хаҗәтләр сорау – мондый зиярәтләр сөннәткә каршы, бәлки кабәхәт бидгать һәм бер төр мәҗүсилек»[34].

Ахырдан әйтәсе килгән сүзебез шул: барлык ташъязма истәлекләребезне кулдан килгәнчә саклап калырга тырышыйк, ягъни үлгәннәрнең каберен, борынгы кабер ташларының кадерен белик!

---

[32] Фәхреддин Р. Җәвамигыль-кәлим шәрехе / Р. Фәхреддин. – Оренбург, 1916. – Б. 224.

[33] Шунда ук. – Б. 368.

[34] Баруди Г. Хәдис: Гыйлемсез галим, төш мәсьәләсе, зиярәте кобур хәдисе. Хатыннарның кабергә зиярәтләре. Әдәбе зиярәт / Г. Баруди // Дин вә әдәб. – 1913. – № 24. – Б. 743.

# КУШЫМТА

## Об отводе земли для кладбища в Адмиралтейской слободе и о назначении для того со стороны Думы депутата[35]

*Лист 1:*

МЮ Казанскаго градского землемера 4 декабря 1848 года

В Казанскую градскую думу

Вследствии общаго присудствия членов градской полиции градской думы, татарской ратуши депута и духовной стороны, медицынскаго чиновника и губернскаго землемера о снятии вновь места для Адмиралтейскаго кладбища с сим вместе я командировал землемернаго помощника Сапожникова почему прошу градскую думу к действию

*Лист 1 об.:*

командировать депутата с тем чтобы на проезд его с Сапожниковым из Казани до места сьемки каждодневно назначалась одноконная подвода с 10 рабочими и поболше.

*Лист 2:*

по сему отношению в градской думе резолюциею заключено: отнестись к Г. губернскому землемеру и покорнейше просить его доставить в думу сведение для каких работ требуются им 10 человек в каждый день рабочих.

*Лист 2 об.* – пустой

---

[35] Национальный архив РТ: ф. 114, оп. 1, д. 2029. Текст приведён в оригинальном (не изменённом) виде.

*Лист 3:*

МЮ Казанскаго градского землемера 21 декабря 1848 года

На отношение думы от 21 декабря по делу отделения и задачи градского выгона участка земли под кладбища руское и татарское адмиралтейской слободы имею честь уведомить что рабочие люди землемерному помощнику Сапожникову нужны для носки цепи астролябии с принадлежностями, ставки пик, рытия ям и переставки столбов

*Лист 3 об.:*

с прежде отведеннаго места на новые граничные повороты.

*Лист 4:*

По сему отношению в градской думе резолюциею заключено: предписать гласному Командирову чтобы он по требованию землемернаго помощника Сапожникова потребное число рабочих людей нанимал и о разсходовании сумм представил думе надлежащую отчетность.

*Лист 4 об.* – пустой

*Лист 5:*

МЮ Казанской губернской чертежной землемернаго помощника Сапожникова 31 генваря 1849 года

В Казанскую градскую думу.

Г. Казанский губернский землемер 4 декабря минувшаго 1848 года, предписал мне отвести место, предположенное для Адмиратейскаго кладбища, при депутате оной градской думы и вместе с тем дал знать что об откомандировании коего в тож время сообщено им в думу, но не имея по настоящее время уведомления об откомандировании де-

путата, я имею честь покорнейше просить оную градскую думу распоряжением таковым поспешить.

*Лист 5 об.* – пустой

*Лист 6:*

Приказали: землемерному помощнику Сапожникову, чтобы он с требованиями своими обратился прямо к гласному Командирову.

*Лист 6 об.* – пустой

*Лист 7:*

МЮ Казанской губернской чертежной землемернаго помощника Сапожникова 3 февраля 1849 г.

В Казанскую градскую думу

Г. Казанский губернский землемер от 24 минувшаго генваря, вследствие отношения Казанскаго полицмейстера, последовавшаго с подтвердительнаго предписания губернского правления, строго подтвердил мне сьемкою новаго места, предполагаемого к отделению из градской выгонной дачи под кладбища руское и татарское близ Игумной слободы, сколь можно поспешнее озаботится и взойти с требованием в оную думу о командировании депутата

*Лист 7 об.:*

с потребными к тому материалами и 10 человеками рабочих людей.

Вследствие чего покорнейше прошу оную думу в согласность отношения моего от 31 минувшаго генваря в думу вступившему, командированием депутата к отводу вышеозначенных кладбищ сколь возможно поспешить, вменив ему в обязанность о заготовлении 10 человек рабочих людей, потребнаго количества для разграничения кладбищ, столбов и к вьезду лошадей.

*Лист 8:*

По сему отношению в градской думе резолюциею заключено: как о назначении со стороны сей думы депутата для бытия при отводе земли под кладбища и о доставлении для того потребнаго числа рабочих людей и материалов распоряжение сделано по отношению землемернаго помощника Сапожникова от 31 января, то настоящее его требование приобщить к делу.

*Лист 8 об.* – пустой

*Лист 9:*

1849 года, майя дня я ниже подписавшийся дал росписку Казанской градской думы гласному Командирову в том что получено мною за доставку по требованию землемернаго помощника Г. Сапожникова для отводу земли в Адмиралтейской слободе под руское и татарское кладбище рабочих людей 10 человек на 1 день по 28 ½ коп. на каждаго, 2 руб. 85 коп. столбов односаженных, толщиною в верс. 8 по 50 коп. 4 руб. за обделку и перевоску их по местам 2 руб. 36 коп. а всего девять рублей, дватцать одна копейка

*Лист 9 об.:*
серебром.

*Листы 10, 10 об.* – то же, что и на л. 9, 9 об.

*Лист 11:*

По сему рапорту в градской думе резолюциею заключено: предписать гласному Командирову удостоверение или квитанцию от землемернаго помощника Сапожникова в действительности употреблении рабочих и материалов.

*Лист 11 об.* – пустой

*Лист 12 об.:*

Квитанция от августа 1849 года (число не указано) от имени землемерного помощника Сапожникова, подтверждающая расходы.

*Лист 12 об.* – пустой

*Лист 13:*

По справке оказалось: вследствие требований г. Казанскаго губернскаго землемера и землемернаго помощника Сапожникова, предписано было гласному Командирову о найме рабочих людей и заготовлении материалов для отвода земли в Адмиралтейской слободе под руское и татарское кладбищи.

Приказали: как из доставленной квитанции землемернаго помощника Сапожникова и отчетности

*Лист 13 об.:*

гласного Командирова видно, что по отводу означенных кладбищ употреблено рабочих 10 человек и 8 столбов, всего на сумму 91 рублей, 21 коп. серебромто выдачу сих денег гласному Командирову из городской суммы исправить.

*Листы 14, 14 об.* – пустые

*Лист 15:*

МВД начальника Казанской губернии по части Гражданской

Отделение 1

Стол 2

12 ноября 1849 года

Казанской градской думе

Вследствие рапорта думы от 3-го ноября, разрешая выдать гласному Командирову девять рублей, двадцать одну копейку серебром из городской суммы в возврат употреб-

ленных им из собственных денег на покупку материалов и наём рабочих

*Лист 15 об.:*

необходимых при отводе места под кладбище в Адмиралтейской слободе даю знать о том думе к исполнению.

*Лист 16:*

Приказали: разрешенныя деньги 9 руб. 21 коп. сереб следующия гласному Командирову в возврат употребленных им из собственности на покупку материалов и наем рабочих людей для отвода места под кладбище в Адмиралтейской слободе, по записке в расход из общих остатков городских сумм, выдать ему Командирову с роспискою.

*Лист 16 об.* – пустой

*Лист 17:*

27 июня 1853 г.

По разсмотрению производившейся в градской думе переписи, начатой 14 декабря 1843 года об отводе для кладбища в Адмиралтейской слободе земли, оказалось что за отводом сказанной земли, с удовлетворением по сему предмету расходов, переписка эта не требует более никакого производства.

Приказали: означенную переписку сдать для хранения в архив.

*Листы 17 об.–19* – пустые

*Лист 19 об.:*

В Казанскую градскую думу от землемернаго помошника.





№ 1



№ 2



№ 3



**№ 4**



**№ 5**



**№ 6**



**№ 7**



**№ 8**



**№ 8а**



**№ 9**



**№ 10**



**№ 11**



**№ 12**



**№ 13**



**№ 14**



**№ 15**



**№ 17**



**№ 16**



**№ 18**



№ 19



№ 20



№ 21



№ 22



**№ 23**



**№ 23а**



**№ 24**



**№ 25**




**Бишбалта бистәсенең планы. 1793 ел**

Россия дәүләт борынгы актлар архивы: ф. 1354, тасв. 138, I бүлек, сак. бер. М 8)

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Әхмәтҗанов М.И. Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 2011. – 215 б.

2. Әхмәтҗанов М.И. XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 2011. – 260 б.

3. Баруди Г. Хәдис: Гыйлемсез галим, төш мәсьәләсе, зиярәте кобур хәдисе. Хатыннарның кабергә зиярәтләре. Әдәбе зиярәт / Г. Баруди // Дин вә әдәб. – 1913. – №24. – Б. 740–746.

4. Джумагулов Ч. Эпиграфика Киргизии. Выпуск 3 / Ч. Джумагулов. – Фрунзе: Изд-во «Илим», 1987. – 168 с.

5. Замалетдинов И.Л. Связь времен в различных календарях. Пособие по переводу дат хиджры на европейское летосчисление / И.Л. Замалетдинов. – Казань: РИЦ «Школа», 1999. – 152 с.

6. История Казани в документах и материалах. XIX век. Книга III: Управление, бюджет, хозяйство / Под ред. И.К. Загидуллина. – Казань: Главное архивное управление при КМ РТ, 2011. – 820 с.

7. Липаков Е.В., Афонина Е.В. История татарских кладбищ: Специальное издание к 1000-летию основания города Казани / Е.В. Липаков, Е.В. Афонина. – Казань, 2005. – 64 с.

8. Мухаметшин Д.Г. Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Серия «Археология евразийских степей» / Д.Г. Мухаметшин. – Выпуск 6. – Казань: Институт истории АН РТ, 2008. – 132 с.: с илл.

9. Поляков С.П., Черемных А.И. Погребальные сооружения населения долины Заревшана / С.П. Поляков,

А.И. Черемных // Домусульманские верования и обряды Средней Азии. – М.: Наука, 1977. – С. 261–279.

10. Россия дәүләт борынгы актлар архивы.

11. Салихов Р.Р., Измайлов Б.И. Адмиралтейская слобода / Р.Р. Салихов, Б.И. Измайлов. – Пенза: ИП Рогожин И.В., 2013. – 100 с.

12. Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше. (Белешмәлек 2005 елның 1 апреленә) / ТР Премьер-министры Р.Н. Миңнеханов редакциясендә. – Казан: Инновация технологияләре үзәге, 2005. – 408 б.

13. Татарстан Республикасы Милли архивы.

14. ТР ФА ТӘһСИнең Язма һәм Музыкаль мирас үзәге.

15. Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр / В.М. Усманов. – Уфа: ДизайнПолиграфСервис, 2005. – 168 б.

16. Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 99.

17. Фәхреддин Р. Җәвамигыль-кәлим шәрехе / Р. Фәхреддин. – Оренбург, 1916. – 552 б.

18. Фахрутдинов Р. Золотоордынский Булгар / Р. Фахрутдинов // Татарская археология. – 2006. – №1–2. – С. 64–82.

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш ..........................................................................................3

Бишбалта зираты тарихыннан ...................................................8

Бистәдә табылган кабер ташлары ..........................................12

Йомгак .........................................................................................44

Кушымта.
Бишбалта бистәсе зираты өчен җир бүлеп бирү
һәм аның өчен Думадан депутат билгеләү хакында
(Об отводе земли для кладбища в Адмиралтейской
слободе и о назначении для того со стороны
Думы депутата) .........................................................................51
Фотолар ......................................................................................57

Кулланылган әдәбият ...............................................................65

*Гайнутдинов Айдар Марсилевич*

**Эпиграфические памятники**
**Адмиралтейской слободы Казани**
*(на татарском языке)*

*Научное издание*

Оригинал-макет – *Л.М. Зигангареева*
Подписано в печать 10.04.2018 г. Формат 60×84 $^{1}/_{16}$
Усл. печ. листов 4,25. Тираж 300 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета

Логос
ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
им. академика В.И. Андреева

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а
Тел./факс: (843) 231-05-46,
231-08-71, 231-04-19
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
Татаровед.рф